КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1127

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

7 пунктның беренче абзацында «Министрлыкка» сүзен «Идарәгә» сүзенә алмаштырырга;

17 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$W_{нi} = V_{нi} \times К \times S_{н}$,»;

18 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$W_{я} = V_{я} \times S_{я}$,»;

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен

каплауга федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

7 пунктның сигезенче абзацында «күчермәләрен» сүзләреннән соң «һәм (яки) Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча кредиттан (заемнан) максатчан файдалануны раслый торган документлар реестрын» сүзләрен өстәргә;

13 пунктның икенче абзацында җөмлә башына «Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин